МИНИСТЕРСТВО ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.07.2015 г.Казань № П-115

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауны үткәрү турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләретурында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясындагы 3 өлеш нигезендә

БОЕРАМ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлаутәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Теркәү, карап тикшерү, үтәүчегә җибәрү, гражданга җавап бирү һәм гражданга җавап бирү вакытларын үтәүне тикшерүдә тоту Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 20.06.2011 елдагы Б-67 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының эш башкару буенча тәгълимнамәсе, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 28.05.2014елдагы Б-61номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына керә торган контроль документларны һәм йөкләмәләрне үз вакытында үтәүне тәэмин итү регламенты нигезендә алып барыла, дип билгеләргә.
3. Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр анализын, Тәртиптә билгеләнгән вакытларда, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының рәсми сайтына(http://mic.tatarstan.ru)«Түләүсез юридик ярдәм/хисаплар» бүлегенә урнаштырырга (Гәрәева Ю.В., килешү буенча).
4. Тәртиптә күрсәтелгән затларга, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү өчен җаваплы затларга гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерүне җайга салучы законнар һәм әлеге Боерык таләпләрен тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә.

5. Гражданнармөрәҗәгатьләрен карап тикшерү вакытларын бозу, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләренә җавапны рәсмиләштерүгә һәм аның сыйфатына таләпләрне үтәмәү Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының бозулар җибәргән дәүләт граждан хезмәткәренә карата дисциплинар җәза кулланууга нигез булып тора, дип билгеләргә.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны министрның беренче урынбасары Ю.Н.Багровка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **Р.А. Шәйхетдинов**

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 2015 елның 21 июлендәге П-115 номерлы

боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына (алга таба – Министрлык) гражданнар мөрәҗәгатьләре керүгә йогынты ясаган сәбәпләрне билгеләү һәм бетерү максатларында эшләнгән һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерүнең һәм аларга анализ үткәрүнең эзлекле тәртибен билгели.

## 2. Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм аларга анализ ясау

2.1. Мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, элемтә тармагы предприятиеләре эшенә мөрәҗәгать-шикаятьләр саны һәм гражданнар соратуларының эчтәлеге өлешендә Министрлыкка кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм аларга анализ ясауны Министрлыкның Элемтә белән оператив идарә итү үзәге-секторы гамәлгә ашыра.

2.2. Кергән, яңадан адресланган һәм карап тикшерелгән мөрәҗәгатьләр, электрон документлар әйләнеше рәвешендәге мөрәҗәгатьләр хакында мәгълүматны үз эченә алган гомумиләштерүне һәм статистик анализны оештыру эшләре һәм эш башкару бүлегенең эш башкару мөдире-өлкән белгеч гамәлгә ашыра.

2.3. Гражданнарны министрның, министрның беренче урынбасарының, министр урынбасарларының шәхси кабул итүенә язуны һәм шәхси кабул итү вакытында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауны электрон хөкүмәтне үстерү секторы өлкән белгече гамәлгә ашыра.

2.4. Тәртипнең 2.1, 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән затлар хисап чоры тәмамланганнан соң 5 эш көне эчендә ай саен Министрлыкның хокукый тәэмин итү секторына әлеге Тәртипкә кушымтага ярашлы рәвештә мәгълүмат җибәрәләр.

2.5. Министрлыкның хокукый тәэмин итү секторыай саен килгән мәгълүматны гомумиләштерүне һәм анализлауны гамәлгә ашыра.

2.6. Анализлау үткәргәндә кергән, яңадан адресланган һәм карап тикшерелгән язма мөрәҗәгатьләр, электрон документлар әйләнеше рәвешендәге мөрәҗәгатьләр саны турында, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре хакында, шәхси кабул итү вакытында кабул ителгән гражданнар саны турында, гражданнарны шәхси кабул итү һәм урыннарга чыгып шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар хакында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар хакында мәгълүмат, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм бүтән актлар (булганда) турында мәгълүмат өйрәнелә.

2.7. Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең гомумиләштерелгән анализын Министрлыкның хокукый тәэмин итү секторы хисап чоры тәмамланганнан соң 10 көн эчендә Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгару өчен ярты елга бер тапкыр боерыкның 3 пунктында күрсәтелгән затка юллый.

2.8. Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең анализы Министрлыкның рәсми сайтында(http://mic.tatarstan.ru/)«Түләүсез юридик ярдәм/хисаплар» бүлегендә һәркем файдалана алырлык ачык мәгълүмат булып тора.

---